**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 3 июнь № 405

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында лизинг рәвешендәге инвестицияләрне үстерү чаралары турында» 2006 ел, 28 февраль, 79 нчы карары белән расланган «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе уставына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында лизинг рәвешендәге инвестицияләрне үстерү чаралары турында» 2006 ел, 28 февраль, 79 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 декабрь, 1088 нче; 2013 ел, 24 июнь, 437 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Предприятие урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Юлиус Фучик урамы, 90а йорты.»;

2.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле унсигезенче һәм унтугызынчы абзацлар өстәргә:

«предприятиеләр һәм учреждениеләр каршындагы ашханәләр эшчәнлеге;»,

«җәмәгать туклануы продукциясе белән тәэмин итү;»;

2.2 нче пунктның унсигезенче абзацын егерменче абзац дип санарга;

3.3 нче пункттагы «622 650,0 мең сум» сүзләрен «174 132 926,0 сум» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\405.doc